| 69-70 | Стилистиканың нигезе буларак синонимия. Морфологик синонимнар һәм аларны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре. | Укытучы сөйләме, конспектлау күнекмәләре. Синонимнарның төп мәгънәләрен һәм мәгънә аерымлыкларын билгеләү. | 20.02<br>21.02 | |
| 71-72 | Синтаксик синонимнар. Сүзтезмәләр һәм җөмләләр синонимлыгы | Грамматик биремле диктант язу. | 23.02<br>27.02 | |
| 73-74 | Бер һәм ике составлы җөмләләр синонимлыгы | Җөмләләрне җыйнаклык таләбеннән чыгып үзгәртеп язу. | 28.02<br>1.03 | |
| 75-76 | Туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы | | 5.03<br>6.03 | |
| 77-78 | Синтетик һәм аналитик җөмләләрнең синонимлыгы | | 8.03<br>12.03 | |
| | | | | |
| | | | | |
| 79 | **Контроль диктант. “Урманда көзге яңгыр”** | Белем һәм күнемәләрне гамәлдә куллана белү | 13.03 | |
| 80-81 | Хаталар өстендә эш. Тезмә кушма җөмләләр синонимлыгы | | 15.03<br>19.03 | |
| 82 | Татар телендә калькалар | | 20.03 | |
| 83 | Сөйләм культурасы, аның нигезләре. Сөйләм төгәл булсын | Укытучы аңлатмасы.<br><br>Күнегүләрэшләү. | 22.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 84 | Сөйләм аңлаешлы булсын | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү һәм сөйләп карау. Караламага язу. | 2.04 | |
| 85 | Сөйләм саф булсын | Укытучы аңлатмасы. Аңлатманың кыскача эчтәлеген язу. Күнегүләрэшләү. | 3.04 | |
| 86 | Сөйләм җыйнак булсын | Укытучыаңлатмасы.<br><br>Күнегүләрэшләү. | 5.04 | |
| 87 | Сөйләм аһәңле булсын | Укытучы сөйләме. Аңлатманың кыскача эчтәлеген язу. Язмаларның кайсы диалектка каравын билгеләү, бу диалектның әдәби әйтелештән аермаларын таба белү. | 9.04 | |
| 88-89 | **Изложение” Исемең матур, кемнәр куйган?”** | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү һәм сөйләп карау. Караламага язу. | 10.04<br>12.04 | |
| **Тел турында гомуми мәгълүмат - 3 сәг.** | | | | |
| 90-91 | Хаталар өстендә эш. Телнең иҗтимагый әһәмияте. Тел һәм тарих.Хәзерге татар милли әдәби теленең тамырлары. | Укытучы аңлатмасы.<br><br>Күнегүләрэшләү. | 16.04<br>17.04 | |
| 92-93 | Татар милли әдәби теленең формалашуы. Татар сөйләмә теленең диалектлары. | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү һәм сөйләп карау. Караламага язу. | 19.04<br>23.04 | |
| 94 | **Орфография һәм тыныш билгеләре. Контроль диктант. “Матур булыйк!”** | Укытучы аңлатмасы. Аңлатманың кыскача эчтәлеген язу. Күнегүләрэшләү. | 24.04 | |
| 95-96 | Икетеллелек. “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Законы. Тел белеменең әһәмияте, төп бүлекләре. | Текстларныукып, татар-гарәп, татар-рус икетеллелегейогынтысынаңлату. “Татарстан Республикасыхалыкларытелләретурында” Татарстан РеспубликасыЗаконыннанөземтәләрнеукыпөйрәнү, кыскачаэчтәлегенязу. | 26.04<br>30.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 97 | **Еллык контроль эш.** | Грамматик биремле диктантны мөстәкыйль язу. | 1.05 | |
| 98 | Хаталар өстендә эш. | | 3.05 | |
| Кабатлау һәм имтиханга әзерлек - 4 сәг. | | | | |
| 99-100 | Тестлар ярдәмендә татар теленнән белем сыйфатын тикшерү, белемнәрне балларда бәяләү | Укытучы укыганны тыңлау, план төзү һәм сөйләп карау. Караламага язу. | 7.05 8.05 | |
| 101 | Тестлар ярдәмендә татар теленнән белем сыйфатын тикшерү, белемнәрне балларда бәяләү | | 10.05 | |
| 102 | Йомгаклау | | 14.05 | |

**Укыту – методик тәэмин ителеш исемлеге. Әдәбият исемлеге.**

**I.Төп әдәбият:1.** Дәреслек: 9 нчы сыйныф өчен ФМ.З.Закиев, В.Н.Максимов тарафыннан төзелгән Казан: Татарстан китап нәшрияты 2015, укыту әсбабына нигезләнеп төзелде.

**2.**М.З.Зәкиев. Н. В. Максимов.Татар теле, 8 сыйныф, татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015

**3.** Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан:“Мәгариф” нәшрияты, 2002.

**4.** М.З.Зәкиев. Н. В. Максимов.Татар теле, 8 сыйныф, татар телендә гомуми белем бирү оешмалары укытучылары өчен методик кулланма.- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2015

**II. Өстәмә әдәбият:**

**1.**Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре. 5-7. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2003.

**2.**Харисова Ч.М. Татар теле. Анализ үрнәкләре. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2009.

**Укучылар өчен тәкъдим ителә торган әдәбият исемлеге**

**1.**Ганиев Ф.Ә. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005.

**Дидактик материаллар1.** Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002.**2.** Таблицалар (гади җөмлә синтаксисы).

**Мәгълүмати-электрон ресурслар1.** "Татар теле. 5-11", "Белем.ру" ҖЧҖ, 2009. Мультимедияле ярдәмлек.**2.** Татар сайтлары: edu.tatar.ru; belem.ru.

**Укыту процессының матди-техник тәэмин ителеше**
**I. Техник чаралар:1.** Ноутбук. 2.Тавышкөчәйткечләр
**II. Программалар:1**. Windows 7 операционсистемасы:MicrosoftOffice 2003,  2007, 2010.MicrosoftOfficePowerPoint

**Эш программасына кушымта.**

**Контроль диктантларны бәяләү критерийләре.**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1 | Орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаган эшкә. **Искәрмә.** Орфографик (яки пунктуацион) 1 хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата, бер үк сүзләрдә кабатланса һәм  пунктуацион 1 хаталы эшкә | "5"ле билгесе куела. |
| 2 | 1орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә. **Искәрмә.** 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | "4"ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | 2 орфографик, 1–3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә.<br>**Искәрмә.** 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | "3"ле билгесе куела. |
| 4 | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | "2" ле билгесе куела. |
| 5 | 6–7 орфографик, 4–5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә | "1"ле билгесе куела. |

***Грамматик биремле диктантны бәяләү***

Грамматик биремле диктантларга *ике билге* куела: беренчесе – диктантка, икенчесе – грамматик биремне башкару сыйфатына. Әгәр грамматик бирем бер дә ялгышсыз башкарылса, эшкә "5"ле билгесе куела. Дүрттән өч өлеше (75%) дөрес башкарылмаган грамматик биремгә уңай билге куелмый.

**Изложениеләрне бәяләү**

Изложение язу өчен, гадәттә, укучыга аңлаешлы телдә хикәяләү характерындагы текст яки өзек алына. Ул матур яки фәнни- популяр әдәбияттан, көндәлек матбугаттан һ.б. булырга мөмкин.

Кайсы гына өзек, текст бирелсә дә, укучы аның язылу стиленә игътибар итәргә. Стильләрне бутамаска тиеш. Текстның стиль үзенчәлекләре укучының язмасында да сакланырга тиеш.

Сайланган текстлар укучыларга белем һәм тәрбия бирү максатларын канәгатьләндерерлек. Эчтәлеге һәм теле ягыннан аңлаешлы булырга, бәйләнешлә сөйләм үстерү юнәлешендә алып барылырга тиеш.

Изложение текстының күләме түбәндәгечә билгеләнә:

| Сыйныф | Изложение саны | Уку елы башында | | Уку елы азагында | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Текстның күләме | язманың күләме | Текстның күләме | язманың күләме |
| 6 | 4(2) | 250-300 | 140-150 | 300-350 | 160-180 |

Изложение ярдәмендә укучыларның түбәндәге белем, осталык, һәм язу күнекмәләре тикшерелә:

1. Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүе, бәйләнешле итеп яза алуы, ягъни изложение текстының мөмкин кадәр төгәл бирелүе.
2. Укучының тел байлыгы, сөйләмнең төгәл һәм образлы булуы. Сөйләм байлыгы дигәндә, предмет, күренеш, вакыйгаларны тасвирлауда тиешле сүзләрне мөмкин кадәр урынлы куллану, күп төрле морфологик категорияләрдән синтаксик төзелмәләрдән файдалану күздә тотыла. Сүз төрлелегенең чикләнгән булуы, сүзнең бер үк формаларын еш кабатлау, бер төрдәге гади җйнак җөмләләләр яки бертөсле синтаксик төзелмәләр беләң генә эш итү укучы теленең ярлы булуын күрсәтә.
3. Грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсе – укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуы ул.

**Изложениеләрне бәяләү критерийләре.**

| № | Текстның бирелеше | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1 | Текст планга нигезләнеп (яки плансыз), эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган; фактик хаталар юк. | 1 орфографик яки пунктуацион ( яки грамматик) хата бар. | “5”ле билгесе куела. |
| 2 | Текстның хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик хата бар. | 2 орфографик 1 пунктуацион ( яки 1 грамматик) хата бар. | “4”ле билгесе куела. |
| 3 | Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган. Сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик хата бар. | 3 орфографик 2 пунктуацион ( яки 1 грамматик) хата бар. | “3”ле билгесе куела. |
| 4 | Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган, стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар бар | Орфографик хаталарның саны – 3 тән, пунктуацион хаталарның саны – 2 дән, грамматик хаталарның саны 3 тән артык. | “2”ле билгесе куела. |

**Контроль – тикшерү материаллары.**

**Кереш диктант.**

**Максат:** укучыларның 8 нче сыйныфта алган белемнәрен тикшерү.
**Бурычлар:**

- Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын үзләштерүләрен бәяләү;
- сүз төркемнәрен һәм җөмлә кисәкләрен билгели алуларын бәяләү.
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Туган тел.**

Якшәмбе көнне Мәскәү татарлары Измаил паркына җыелалар. Өч ел шушы паркка мин дә йөрдем. Йөз яшьлек юкә агачлары урап алган мәйданда өздереп тальян гармун уйный. Яшь егетләр, яшь кызлар гармунга кушылып җырлыйлар, әйлән-бәйлән уйныйлар, бииләр. Авылда чакта уен җырларын күп тыңладым мин . Авыл җирендә күбрәк мәхәббәт, яшьлек турында, аның заяга үтүе, бәхетнең кыска гомерле булуы турында җырлыйлар иде. Бу бакчада исә авылны сагыну, туып-үскән җирләрне юксыну моңнары өстенлек итә. Югыйсә, минем милләттәшләрем монда үзләре теләп килгәннәр. Әйе, шәһәрдә тормыш уңайрак. Эш-хезмәте дә җиңелрәк. Монда музейлар, театр, концерт заллары.Ә шулай да татарлар һәр атна менә шушында җыела.Туган телдә сөйләшә, җыр тыңлый.

Туган тел! Үзәкнең иң түренә кереп утырган әрнүле, татлы бер тылсым! Синең гармун ыңгырашуы аша колакка килеп бәрелгән бер сүзең яшәүнең мәгънәсен көчәйтеп җибәрә, күңелне пакьләндерә, хыял-өметләрне тергезә, тормыштагы авырлыкларны, гаделсезлекләрне

җиңеп чыгарга көч өсти. "И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!" - дип юкка гына әйтмәгән бөек шагыйрь. (154 сүз)

## Изложение.

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;
- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

## Ике дус.

Биологиядән “ ике” ле алуына һич үкенмәде Камил, чөнки бу фәнне башкаларга караганда яхшырак белә. “Ике” ле алуның сәбәбе дә көлке сыман: контроль эш дәфтәрен күрептапшырмаган. Эшен беренче булып төгәлләгән иде дә, янәшә партада утыручы Сәриянең биремне эшли алмавын күреп, укытучы сизмәгәндә генә, дәфтәрен аңа сузды. Дәрес бетеп, тәнәфескә кыңгырау шалтырагач, укытучы үзе йөреп җыйды дәфтәрләрне. Минем дәфтәр Сәриядә дип әйтмәс бит инде!

Укытучы Галия Нуровна икенче көнне иртән дәфтәрләрне өләшеп чыкты да журналдан Камилнең фамилиясен эзләде.

- Шәкуров, синең эшеңә “ике”ле, - диде.
- Ни өчен “ике”ле соң ул, Галия Нуровна? – дип сорады Камил елмаю катыш.
- Дәфтәреңне тапшырмагансың!

Сыйныф бүлмәсендә тынлык урнашты. Мин Камилнең белгәнен дә, контроль эшен беренче булып язып бетерүен дә яхшы беләм. Без Камил белән дуслар, бер партада утырабыз.

Сәрия гафу да үтенмәде, Камил дәфтәреннән күчереп язган контроль эшенә “биш” ле алды.

Мәктәптән без икебез генә кайттык. Авылга өч чакрым юл. Камил миңа табигатьтәге үсемлекләр, бөҗәкләр,кошлар, җәнлекләр дөньясы турында сөйләде. Каян барысын да истә калдыра ул! (156 сүз)

(Дания Гайнетдиновадан)

## Изложение.

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;
- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Чәчәк.**

Булган, ди , бер Чәчәк. Сабагында утырган-утырган да әйтеп куйган бу:

-Җил мине төрле якка селкетә, Кояш кыздыра, ул кыздырганда, күләгәгә дә яшеренеп булмый, туйдым бу сабакта гына утырудан, - дигән.

Бүтәннәр аның белән бәхәсләшмәгәннәр. Аларга сабакта утыру да, җил искәндә чайкалу да, кояшта кызыну да, кичке җиләс һавада таҗларын йомып йокыга талу да бик рәхәт булган.

Шул арада болынга бер кыз йөгереп килгән дә әлеге Чәчәкне, өзеп, түшенә кадаган. Чәчәк куанычыннан нишләргә дә белмәгән.

-Күрдегезме, мин хәзер барыгыздан да өстәрәк, биектәрәк! Мин Кояшка да, Җилгә дә якынрак, хәзер мин аларның үзләренең кирәген бирәм! – дигән.

Тик Җилне туктата да, Кояшны суыта да алмаган, үзе генә сулган. Кызның түшеннән чүп үләннәре арасына төшеп калгач, Җил аны очыртып алып киткән дә болынга илтеп ташлаган.

Чәчәкнең күзләреннән яшьләр тамган. Сабагына кире кайтып утырыр иде дә, соң булган шул. Бүтән гөлләр аңа:

-Кояш һәм җил белән кем көрәшә соң? – дигәннәр. – Кояш белән Җил булмаса, без беребез дә үсмәс идек. Җил безнең орлыкларны тирә-якка тарата, Кояш безнең таҗларыбызны кирәк чакта ачтыра, кирәк чагында йомдыра.

Кояш та, Җил дә Чәчәкне ачуланмаганнар. Җир аны үз кочагына алган. Җил Яңгырны чакырган. Яңгыр явып үткәч, бу урында бер генә түгел, әллә ничаклы чәчәкләр үсеп чыккан.

Әлеге Чәчәкнең орлыкларыннан үсеп чыкканнар алар. (149 сүз)

(Сәмига Сәүбәнова буенча)

**Изложение.**

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;

- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Рәбига әби.**

Рәбига әбине яңа өйгә күчергәч, 8 нче сыйныф укучылары моңаеп калдылар. Аларга эш бетте. Элек Рәбига әбигә утын кисәләр, су китерәләр, ишегалларын җыештыралар иде. Рәбига әбинең җиз самоварында чәй кайный, табасында коймак чыжылдый башлый иде. Бу яңа йортта бер эш юк. Су торбадан агып тора. Газ кергән. Идәннәре шома. Тәрәзәләре зур. Тик Рәбига әби генә боегып калды. Укучылар аптырадылар:

-Рәбига әби, әллә өйне яратмыйсыңмы? Хәзер син бик моңсу, - диделәр.

-Өйне бик яраттым, балалар. Иске өемдә минем яшьлегем калды, - дип җавап бирде әби.

Рәбига әбиләрнең иске өе янында миләш үсеп утыра. Аны алар яшь чакларында карты белән бергә утыртканнар. Көз көне балалар шул миләшне әбинең яңа өе каршына күчереп утырттылар. Әти-әниләре дә булышты. Тәрәзәсе каршында яшьлегендә үзе үстергән миләшне күргәч, Рәбига әби чынлап яшәреп китте. Элеккечә яулыкларын чөеп бәйләде, җыр сузды, нәни дусларын елмаеп каршылады. Миләш һәр иртәне Рәбига әбине тәрәзәсеннән үрелеп карый, башын күккә борып, аяк очларына баса-баса, язны көтә.

**Контроль диктант.**

**Максат:** укучыларның 2 нче чиректә алган белемнәрен тикшерү.
**Бурычлар:**
- Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын үзләштерүләрен бәяләү;
- Укучыларның кушма җөмлә һәм катлаулы кушма җөмлә темаларын ничек үзләштерүләрен бәяләү.
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Нәрсә ул СПИД?**

СПИД-специфик вируслар китереп чыгарган һәм дәвалауга бирешмәүчән йогышлы авыру.

Вирус кешенең канына үтеп керә һәм организмның иң мөһим саклану чарасы булган ак кан тәнчекләрен, ягъни лимфоцитларны зарарлый. Нәтиҗәдә, СПИД йоктырган кеше төрле авырулар китереп чыгаручы микробларга, яман шешләргә бирешүчән булып кала.

Авыру организмга акрын тарала. Кайбер лимфатик төеннәрнең зураюы авыруның берничә ел буена бердәнбер билгесе булып торырга мөмкин.

Соңыннан тән температурасы күтәрелә, эчәкләр эшчәнлеге бозыла, авыру нык тирли, ябыга башлый. Алга таба үпкәләр ялкынсына, кан агулана, яман шешләр барлыкка килә, тире үлекләп бозыла башлый. Шуннан соң кеше үлә.

СПИД белән кемнәр авырый?

СПИД белән авыручы кешеләрнең күбесе тәртипсез җенси тормыш белән яшәүче ирләр һәм хатын-кызлар, уртак шприцлардан

файдаланучы наркоманнар һәм СПИД белән авыручы аналардан туган балалар.

СПИДтан ничек сакланырга соң?

Очраклы җенси бәйләнешләр булдырмаска.

Очраклы шприцлардан файдаланмаска.

Нинди дә булса шик туганда, врачка мөрәҗәгать итәргә.

Истә тотыгыз:сезнең үз-үзегезне тота белүегез СПИДтан саклануның иң ышанычлы чарасы булып тора. (146 сү

**Изложение.**

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;
- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Гадилә.**

Кечкенә чакта Гадилә белән Шәһрәт су коенырга бик яраталар иде. Әниләренең эшкә киткәннәрен генә саклап торалар да күл буена чабалар. Гадилә йөзәргә бик ярата иде.

-Кара әле, Шәһрәт, мин әнә теге төнбоек яфрагын кереп утырса, күтәрә алыр микән? – ди ул.

-Юләр, әллә үзеңне бик җиңел дип беләсеңме? Төнбоек яфрагы түгел, мин дә көчкә күтәрәм бит сине.

Сөйләшеп утырганнан соң, алар тагын су коеналар, комда кызыналар. Күлдән төнбоек чәчәкләре җыялар. Гадилә ак төнбоекларны бик ярата. Ул яр башына менеп карап утыра-утыра да, еракта матур чәчәк күреп, кинәт күлгә сикерә. Гадиләне сихри ераклык, күл эчендәге гүзәллек үзенә тарта.

Бервакыт Гадилә күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга уйлады. Күл өстендә сарылы-аклы төнбоеклар шулкадәр күп, әйтерсең зәңгәр күлгә янып торган йолдызлар таратып ташлаганнар. Гадилә шул җем-җем итеп тора торган йолдыз чәчәкләрне өзеп ала да чәчәләренә кадый. Ә чәчкәләре эчкә кергән саен матуррак. Вак дулкыннар өсләрен су белән коендырып китсәләр, алардан да гүзәл, алардан да сокланрыч нәрсә юк төсле. Яр өстеннән караганда, Гадилә төнбоеклар арасыннан күренми дә диярлек. Чәченә күп итеп чәчәкләр кадагач, үзе дә чәчәк бәйләменә охшап киткән. (177 сүз)

(Фәнис Яруллиннан)

**Изложение.**

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;

- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Нәкый Исәнбәт...**

Сынаганыгыз бардыр: кайбер исемнәрдә ирексездән игътибарны үзенә тарта торган ниндидер бер көч була. Андый исем һәрвакытта кызыксыну уята, гел нидер көтәргә мәҗбүр итә... Моның сере, әлбәттә, исемнең үзендә түгел, ә иясендә. Халык әйткәнчә, исем кешене бизәми, ә кеше үзе исемен бизи. Бу хакыйкать Нәкый Исәнбәткә аеруча туры килә: ул үзе, бары тик үзе, исемен олы, шәрәфле, хөрмәтле итте.

Нәкый Исәнбәт дигәч тә, без драматург, шагыйрь, галим бер кешене күз алдына китерәбез. Менә ярты гасырга якын инде без аның җыйнак, ягымлы исемен әдәбиятыбызда өзлексез күреп, театрларыбызда елдан-ел ишетеп киләбез. Ул Тукай исән вакытта ук яза башлый. Шуңа күрәдер ахрысы, гүя Тукайның үз кулыннан әдәби эстафетаны алып, бүгенге көнгә китереп җиткергән карт, әмма армас чапкын булып тоела ул безгә...

Кыска бер мәкаләдә Нәкый Исәнбәтнең гасырга якын гомерен, күп тармаклы иҗади эшчәнлеген һәм тау кадәр хезмәтен азмы-күпме тулы итеп язып чыгу- минем өчен гаять авыр бурыч. Ләкин бер нәрсә күңелне юата: халкыбыз Нәкый Исәнбәтнең кем икәнен бик яхшы белә. Ул аны үзенең иң өлкән, иң күренекле милли язучысы итеп таный, ярата һәм хөрмәт итә.

Халык күңеленә юл салу ансат эш түгел: язучыдан саф вөҗдан, чын гаделлек, искиткеч зур тырышлык һәм батырлык сорый ул. Исәнбәтнең гомер юлы-моның ачык мисалы.

...Без бик хаклы рәвештә Нәкый Исәнбәтне галим дибез. Аның гыйльми хезмәтләре әдәби хезмәтләреннән һич тә ким түгел. Иң элек, ул тел хәзинәбезне өйрәнүдә, туплауда, тәртипкә салуда бик күп эш эшләде. Аннары халкыбызның фольклор байлыгын җыю, өйрәнү эшенә гаять зур хезмәт куйды. Хәзерге вакытта калын томнар булып чыга башлаган халык мәкальләре җыелмасын әнә шул олы хезмәтнең беренче зур, җитди нәтиҗәсе итеп карарга кирәк. Болар өстенә тагын язучының кулында озак еллардан бирле җыелып, томнар тәшкил итәрлек дәрәҗәдә тупланган, гыйльми нигездә тәртипкә салынган татар мәзәкләре, табышмаклары, җырлары, такмазалары бар. Инде без аның борынгы әдәбият язмаларын өйрәнү, аннары драматургия, поэзия буенча теоретик макаләләр язу кебек хезмәтләрен дә искә алсак, бу затның эшләнлегенә гаҗәпләнмичә һәм сокланмыйча һич мөмкин түгел... Әдип балалар әдәбияты буенча зур хезмәтләрне һәм классик язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итүе белән дә танылды.

Нәкый Исәнбәт–тынгысысз язучы. Аның иҗат юлы тап-такыр да шоп-шома гына булмады. Заманыбызның катлаулы чорлары аша узганда, ул сөртенеп, тайгалап та куйгалады. Моның өчен каты тәнкыйтьләрне дә ишетте. Кайбер очракларда исә нахакка да кыйналды. Әмма нинди генә сынауларга дучар ителмәсен, һәрвакытта туган халкына итагатьле, халкының бөек максатларына тугрылыклы булып калды.

Нәкый Исәнбәт–көчле кеше. Ярты гасырдан артык гомерен авыр иҗат эшенә бирде. Аңа татар халкының мәхәббәт-хөрмәте мәңгегә яшәр.

Ә.Еники ”Хәтердәге төеннәр” 400 сүз

**Контроль диктант.**

**Максат:** укучыларның 3 нче чиректә алган белемнәрен тикшерү.
**Бурычлар:**

- Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын үзләштерүләрен бәяләү;
- Укучыларның кушма җөмлә һәм катлаулы кушма җөмлә темаларын ничек үзләштерүләрен бәяләү.
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Урманда көзге яңгыр.**

**Урманның матурлыгын, мәгънәлеген, акылын beləсегез килсә, аның эченә көзге вак яңгыр яуганда керегез.**

Карт юкәләр, вак яңгыр яуганда тамчыларын үзләренә җыеп, акрын гына шыбырдашып утыралар. Әле яфрак бар, әмма инде соңгы атналар якынлаша. Каен инде, саргаеп, яфрак коя; яфрагын койган чыбыклары күксел-шәмәхә төскә керә бара. Бу вакытта авыл халкы аларны җыя һәм себерке бәйли.

Юеш киртәле печән кибәннәре, җиләк исе, хушбуй исе бәреп торган коры ылыс түшәлгән чыршы төпләре – барысы да көзне көтеп уйга калган. Шулар янында көз килүен тыңлап тору рәхәт тә, сагышлы да. Киләсе елда шулай күрешә алырбызмы? Без исән булырбызмы? Чыршы агай, сине йорт бүрәнәсенә дип кисмәсләрме? Ә сез, печән кибәннәре, киртә буена килгән биек аяклы, кара ахак күзле беркатлы поши малайларына, кызларына бездән сәлам әйтегез. Әй сез, чыбыклы юл буендагы чокырлар! Сезнең иңкүлектә уйнаган төлкеләргә әйтегез: сак булсыннар, аучы килүен сизми калмасыннар!

Вак яңгыр сибәли дә сибәли, ә йөрәккә шундый рәхәт. Кычкырып бер җырлыйсы, шушы гүзәл мәһабәтлеккә гимн җырлыйсы килә.

**Изложение.**

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;
- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Исемең матур,кемнәр куйган...**

Исемнәребез, аларның күркәм булырга тиешлеге турында сүз байтактан бара. Ләкин исем сайлаудагы битарафлыкны җиңү бик ансат түгел. Кайсыбер кеше белән танышканда аның мөлаем йөзенә, матур кыяфәтенә карыйсың да, исемен ишеткәч, хәйран каласың. Ул сиңа:
-Рәкыйп, - дип кул суза.

Ә бит Рәкыйп - көндәш, дошман, куралмаучы дигән мәгънәне аңлата.
Мин бик сылу ханымны беләм. Исеме аның - Дәрига. Дәрига сүзе безнең борынгы әдәбиятта бик еш очрый. Анда:

И дәрига, дәрига
Дәригадыр ла бу бала!-

дигән шигъри юллар да табарга мөмкин. Бу инде безнең хәзерге телебезгә әйләндереп әйтсәк:

И кызганыч, кызганыч,
Кызганыч ла бу бала! - дигәнне аңлата. Ә мин белгән Дәрига һич кенә дә андый кызгануларга мохтаҗ кеше түгел.

Кайдан килә соң мондый исемнәр? Нишләп без аларны йөртәбез?
Элегрәк исемне муллалар сайлый торган була. Аерым очракта алар исемне үз белдекләре белән кушып китәргә яратканнар. Ә хәзер?..Хәзер бит бөтенләй башка хәл. Дөрес, исемнең ничек кушылуына бала гаепле түгел. Бу- ата-ананың иң изге бурычларыннан берсе. Әйтик, Бөек Ватан сугышына кадәр шалтыравык исемнәр уйлап табу бик модага кереп киткән иде. Менә берничә генә мисал. Солтан исемле берәү, тота да улына Натлос дигән исем куша. Бу инде, янәсе, үз исеменең киресе. Ләкин моннан һичбер мәгънәгә ия булмаган бернәрсә килеп чыгуында ата кешенең кайгысы юк. Яки кызлар арасында Фәна дигән исем очрый. Бу исә бетү, үлү дигәнне аңлата торган сүз. Әйе, карап туймаслык сылу бер кыз ни эшләргә тиеш? Әгәр аның исеме Нурдидә (күз нурым), Мәхбүбә (сөекле хатын-кыз), Маһруй (ай йөзле, нурлы), Җәмилә (матур), Дилбәр (сөелә торган, күңелне үзенә тартучы кыз), Тәмиз (пакь), Сәхипҗамал (матурлык иясе), Фәсахәт (гүзәл, матур), Һәдия (бүләк), Зөләлә (саф су), Сәгадәт (бәхет иясе, чибәр) кебегрәк булса, яхшырак булмас иде микәнни?! Ул чорда төрлечә мавыгып, машина детальләрен, әллә нинди ят сүзләрне исем итеп алу кебек хәлләр дә булмады түгел.

Бервакыт шундый сөйләшү ишетергә туры килгән иде:
-Улыңа нигә алай начар исем куштың? - дип сорауга, баланың атасы:
-Һәй, ярамаган тагын бала-чагага! - дип җавап биргән иде.

Бала-чагага?! Соң ул бала үсә бит! Егет тә була, гаилә башлыгы да....Исем дә күктә йөзгән ай түгел, япа-ялгыз яши алмый. Ул ата исеме белән, фамилия белән бергә яши. Алай гына да түгел. Малай исеме соңыннан кушылып йөртелә. Әгәр берәү хаталанып улына Танкер яки Руль кушкан булса, ул кешеләр үскәч, аларның нинди хәлдә калачагын күз алдына китереп карагыз. Әле шунысы бар: үзенә кушылган матур исемне кеше бозып, ат мөгезе чыгарып йөрмәсен иде. Фазилә, Фатыйма, Фәһимә, Рәисә, Рәсимә, Рәхимә, Зәйтүнә, Зәйнәп, Зәбирә һәм башка менә шундый гаҗәп соклангыч матур исемнәрне безнең хатын-кызларыбыз Фая, Рая, Зоя кебек кушаматларга әверелдереп бетерәләр. Безнеңчә, моның һич кенә дә кирәге юк.

Исем сайлаганда шулай да телгә ятышлы, матур яңгыравыклы исемнәрне алу кирәктер. Бездә, мәсәлән, хәзерге вакытта Венера- иң күп таралган исемнәрнең берсе. Венера, әлбәттә, матур исем. Ул - борынгы римлылар мифында матурлык һәм мәхәббәт алласы дигәнне аңлаткан. Шул исем белән аталып йөртелгән планета да бар. Һәрхәлдә, кешенең исеме мәгънәле дә, матур да булсын. Аңа бит әнә шул бер исем белән гомер юлы үтәргә туры киләчәк. Исем - кием түгел. Аны теләгән бер вакыта алмаштырып булмый.

**Контроль диктант.**

**Максат:** укучыларның 4 нче чиректә алган белемнәрен тикшерү.

**Бурычлар:**

- Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен һәм алар янында тыныш билгеләренең куелышын үзләштерүләрен бәяләү;
- Укучыларның кушма җөмлә һәм катлаулы кушма җөмлә темаларын ничек үзләштерүләрен бәяләү.
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү.

**Матур булыйк!**

Ханымнар һәм туташлар! Чибәрлек сезнең үз кулыгызда. Матурлык өләшкән җиргә алдан йөгергәннәр дә чибәр күренмәскә мөмкин, чөнки чын чибәрлек – киңрәк төшенчә. Борын-борын заманда бер аксакал, дөнья белән хушлашыр алдыннан, кызларына болай дигән ди: “Мин - ярлы кеше, сезгә мирас итеп яхшы киңәштән башка бернәрсә дә калдыра алмыйм; хәлегездән килсә - акыллы булыгыз, теләгегез булса - кешелекле булыгыз, ә менә матур булу – сезгә зарур.”

Кешеләр элек-электән матурлыкка битараф карамаганнар. Халыкның бер мәкале: ”Матур булып туганчы, бәхетле булып ту”, - дисә дә, тышкы күркәмлек – тормышта гаять әһәмиятле нәрсә. Тышкы күркәмлек гәүдә төзелеше үзенчәлекләренә, баш, йөз формасына, үз-үзеңне тоту һәм атлап йөрү рәвешенә, башка кшеләр белән мөнәсәбәтләрнең нииндилегенә карап билгеләнә. Шушы сыйфатларның камиллеге без омтыла торган матурлык була инде. Әйтелгәнчә, матур булу өчен тышкы күркәмлек кенә җитми; бәлки рухи байлык, интеллект, нечкә зәвык, чама хисе һәм яхшы күңеллелек матур итә кешене.

Матур булыйк дисәк, чиста-пөхтә киеник, чамасын белеп кенә бизәник, үзебезне һәрвакыт әдәпле тотыйк, башкаларга игътибарлы булыйк, шулвакытта без һәркемгә сөйкемле, нәзакәтле күренербез. *(156сүз)*

**Изложение.**

**Максат:** Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүен, бәйләнешле итеп яза алуын, ягъни изложение текстын мөмкин кадәр төгәл бирә алуын тикшерү.

**Бурычлар:**

- Укучының тел байлыгын, сөйләменең төгәл һәм образлы булуын, бирелгән текстның планын төзи алуын бәяләү;
- укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуын бәяләү.
- Текстның стиль үзенчәлекләренең саклануына игътибар итү;
- Орфографик һәм пунктуацион нормаларның үтәлешен бәяләү;

**Илһам чишмәсе .**

Бу кыйсса якташым һәм сабакташым- яшьлек дустым – Илһам турында. Мин аны яшьлеккә хат дип тә атар идем. Консерваториядә бергә укыган яшьлек дусларым хәзер инде барысы да диярлек күренекле шәхесләр , татар музыка сәнгатенә зур өлеш керткән талант ияләре: мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров, композиторлар Мирсәет Яруллин ,Фасил Әхмәт һ.б.

Яшьлек дустыгыз , ерак һәм урау сәфәрләрдән соң,сезгә хат яза, сезне сәламли,талантыгыз алдында баш ия. Исемдә,бик күп бәйрәмнәр, кичәләр, концертлар – барысы да исемдә , исемдә ... Кичәләрнең үзәгендә – Илһам иде . Ул тапкыр сүзле дә, шаян да, наян да. Аңа киң күңеллелек, юмартлык, табигый артистизм хас. Шул ук вакытта ул сабыр холыклы һәм акыллы. Ничектер тормыш ыгы-зыгысыннан өстен.

Хәтеремдә, минем апамның иске патефоны һәм тәлинкәләре бар иде. Илһам аларны кат-кат тыңлый, уйланып утыра. Бик күп җырларга ул яңа тормыш бирде . Аның һәрбер яңа җыры - ачыш, ә тыңлаучы өчен бәйрәм, халык аларны күтеп ала ,тыңлап туя алмый иде. Бу кадәр талант, моң аңа кайдан килә соң ? Моны аңлар өчен Илһамның туган авылында булырга кирәк. Барысы да шунда –Яңа Бүләктә туган.

Туган якларда каникулда булганда , ул бервакыт яшьләрне кунакка чакырды.

Күрешеп, чәйләр эчеп сөйләшкәч, Илһам безне үзенең урман-кырларын,серле чишмә һәм күлләрен күрсәтергә алып китте.Урманга барганда ук җырлый-җырлый,уйнап –көлеп бардык .

Тагын бер кабатланмас мизгел: урман кырларында арыш басуы. Җәй уртасы. Төш вакыты.Тулып килгән башаклар ,тоташ диңгез булып, кояш нурларында иркәләнә, дулкынлана.Тын. Әмма бу тынлыкта колакка ишетелеп-ишетелмәс кенә моң чайкала. Без юл буенда ял итеп утырабыз һәм, телсез калып шушы илаһи тынлыкны бозарга кыймыйча, арыш басуын күзәтәбез. Илһамның йөзендә бәхет һәм бу гүзәл дөньяга мәхәббәт : ”Мин җәйне һәрвакыт менә шулай күз алдына китерәм “ ,- диде ул . Өстәп, арыш басуына тулы бер мәдхия җырлады.

Аннары без чишмәгә – авылда “Илһам чишмәсе”дип аталган җиргә киттек. Ул урман ягында , авылның икенче тарафында әрәмәлектә, куаклар арасында, үзенә күрә аерым матурлыкка ия урында тибеп чыккан. Ни өчен Илһам чишмәсеме? Кайчандыр аны Илһам чистартып рәткә керткән булган , шуннан авыл халкы аны “ Илһам чишмәсе ”дип йөртә башлаган. Ә суы !..Суы нинди тәмле ! Мондый тәмле сулар эчеп үскәч, ничек матур җырламасын инде ул?

Кичкырын авылның тагын бер матур почмагына - авыл очында урнашкан күлгә - балык тотарга алып барды безне Илһам. Шактый гына зур һәм тирән күл ,тирә-ягы агачлык, гаҗәеп матур. Балык эләккәндерме - хәтерләмим. Әмма кайтканда күл буенда урнашкан бакча аркылы кайттык. Әлбәттә, Илһам күл буйларын яңгыратып җырлады , бакчадагы сандугачлар, тын алып, аны тыңлады.

Менә шулай төгәлләнде бу көн .Сафлык , илаһи моң , Илһамның киләчәккә якты өметләре белән сугарылган иде ул.

(Н.Мәрдәни) (499 сүз)

**Контроль диктантларныбәяләү**

| т/с | Таләпләр | билге |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Орфографикһәмпунктуационхаталарбулмаганэшкә<br>Искәрмә:орфографик(яки пунктуацион) хаталыпөхтәбашкарылганэшкә яки берүк хата берүксүзләрдәкабатлансаһәмпунктуационберхаталыэшкә | “5”лекуела<br><br>“5”лекуела |
| 2 | 1орфографик, 1пунктуацион хаталыэшкә<br>Искәрмә:1орфографик, 2пунктуацион хаталыэшкә яки орфографикхаталарыбулмыйча, 3пунктуацион хатасыбулганэшкә, яки бертөрдәге 2 орфографикһәм 1пунктуацион хаталыэшкә | “4”лекуела<br>“4”лекуела |
| 3 | 2 орфографик.1-3пунктуацион хаталы, 2төзәтүле эшкә<br>Искәрмә: 4пунктуацион,1орфографик хаталыэшкә яки<br>Бертөрдәге 5орфографик,4пунктуацион хаталыэшкә | “3”лекуела<br>“3”лекуела |
| 4 | 5орфографик, 5пунктуацион хаталы, 4төзәтүле эшкә | “2”лекуела |

**Грамматик биремле диктантларны бәяләү.**

Грамматик биремле диктантлар күләме ягыннан, контроль диктантлар белән чагыштырганда, 10-15 сүзгә кимрәк була. Аларны тикшерү һәм бәяләү контроль диктантлардагы кебек эшләнсә дә, мондый диктантларга ике билге куела: беренчесе - диктантка, икенчесе - грамматик биремне башкару сыйфатына.

Грамматик бирем бер дә ялгышсыз пөхтә башкарылса, “5” ле куела.

Грамматик биремдә 1-2 хата булса,”4” ле куела

Грамматик биремдә 3-4 хата булс, “3” ле куела.

Грамматик биремдә 5 тән артык хата булса, “2” ле куела.

**Сүзлек диктантларын бәяләү**

Сүзлек диктантының күләме 35- 40 сүз булырга тиеш

Хатасызбашкарылганэшкә “5”лебилгесекуела

1-2 хаталыэшкә “4”лекуела

3-4 хаталыэшкә “3”лекуела

**Изложение түбәндәгечә бәяләнә:**

| т/с | Текстныңбирелеше | грамоталылыгы | билге |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Текст, планганигезләнеп(яки плансыз),эзлеклебирелгән; стиль бердәмлегесакланган; фактик һәм техник хаталарюк | 1орфографик яки пунктуацион(яки грамматик)хата бар | “5”лебилгесекуела |
| 2 | Тексттагыхикәяләүагышыбирелгәнэзлеклелекбеләнтулысынча туры килми; стиль бердәмлегендәхилафлыксызелә; язмадабер фактик, бер техник хата бар | 2орфографик, 1пунктуацион(яки 1грамматик)хата бар | “4”лебилгесекуела |
| 3 | Текст язмадаэзлеклебирелмәгән, стиль бердәмлегесакланмаган, сүзләрбәйләнешендәгетөгәлсезлекләрҗөмләнеңмәгънәсенбозугакитергән; язмада 1 фактик, 2техник хата бар | 3орфографик, 2пунктуацион(яки 1грамматик хата бар) | “3”лебилгесекуела |
| 4 | Тексттагыэзлеклелекязмадасакланмаган; стиль бердәмлегеюк, сүзләрһәмҗөмләләрбәйләнешендәхаталар бар; фактик һәм техник хаталаркүп | Орфографикхаталарның саны өчтән, пунктуационхаталарның саны икедән, грмматикхаталарның саны өчтәнартык | “2”лебилгесекуела |

**Өйрәтү характерындагы язма эшләрне бәяләү**

Өйрәтү характерындагы язма эшләр(төрле күнегүләр, контроль характерда булмаган диктантлар һ.б) контроль эшләр белән чагыштырганда, таләпчәнрәк бәяләнә. Андый эшләрдә:
А)укучының аны ни дәрәҗәдә мөстәкыйль башкаруы;
Б)укытуның кайсы вакытында(яңа белемнәрне үзләштерүгә әзерлек вакытында, үзләштерү процессында, ныгыту яки кабатлау барышында, фронталь тикшерү чорында эшләнүе;
В)эшнең күләме;
Г) ни дәрәҗәдә пөхтә һәм үз вакытында башкарылуы исәпкә алына.
Җибәрелүе ихтимал булган хаталар алдан искәртелгән очракта “5”ле билгесе ялгышсыз, “4”ле билгесе бер төзәтүле(укучы үзе төзәткән) эшкә куела. Ике хатасы булган эшкә”3”ле, 3-4 хаталы эшкә “2”ле куела.

**Сочинение түбәндәгечә бәяләнә**:

| | **Эшнеңэчтәлегеһәм теле** | **Грамоталылыгы** | **билге** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Эчтәлектемага туры килә; язмада фактик ялгышларюк; план буенча (яки плансыз) эзлеклеязылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлегесакланган | 1орфографик(пунктуационяи сә грамматик)ялгыш бар | “5”лекуела |
| 2 | Язманыңэчтәлегетемаганигездә туры килә. Ул дөресачылган; 1фактик хата җибәрелгән,хикәяләүэзлеклегендәартыкәһәмиятлебулмаганбозылусизелә; тулаемалганда,телебай,образлы,стилбердәмлегесакланган | 2орфографик,2пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар | “4”лекуела |
| 3 | Эчтәлекнебирүдәмөһимчитләшүләр бар: улнигездәдөрес,ләкин фактик төгәл-сезлекләрочрый.хикәяләүэзлеклетүгел; телнеңярлылыгысизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана. Бертөрлерәксинтаксиктөзелмәләрфайдалана, образлыүгел. Сүзкулланудаялгышларҗибәрә; стиль бердәмлегесакланыпҗитмәгән | 3орфографик, 3 пунктуационһәм 3 грамматик ялгыш бар | “3”лекуела |
| 4 | Тема ачылмаган; фактик төгәл-сезлекләркүп; планга туры килми.эзлеклелекбозылган; теле ярлы; сүзкулланyялгышлары еш очрый; стиль бердәмлегеюк. | 7орфографик,7пунктуационһәм грамматик ялгышлар бар | “2”лекуела |

**Нормы и критерии оценки диктантов, сочинений, изложений**

**Требования к тексту диктанта**

| | | |
|---|---|---|
| | **Количество в диктанте** | |

| Класс | Слов | Орфограмм | Пунктограмм | Слов с непроверяемыми орфограммами | Количество слов в словарном диктанте |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | 90 – 100 | 12 | 2 – 3 | 5 | 15 – 20 |
| 6 | 100 – 110 | 16 | 3 – 4 | 7 | 20 – 25 |
| 7 | 110 - 120 | 20 | 4 – 5 | 10 | 25 – 30 |
| 8 | 120 – 150 | 24 | 10 | 10 | 30 – 35 |
| 9 | 150 - 170 | 24 | 15 | 10 | 35 – 40 |

**Таблица 2**

**Нормы оценивания диктантов**

| Нормы оценок (количество ошибок) | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Вид диктанта | **«5»** | **«4»** | **«3»** | **«2»** |
| Контрольный | 1 негрубая орфографическая + 1 негрубая пунктуационная | - 2 орфографические + 2 пунктуационные;<br>- 1 орфографическая + 3 пунктуационные;<br>- 0 орфографических + 4 пунктуационные | - 4 орфографические + 4 пунктуационные;<br>- 3 орфографические + 5 пунктуационные;<br>- 0 орфографические + 7 пунктуационные;<br>- 6 орфографические + 6 пунктуационные (если есть однотипные и негрубые орф. и пунк. ошибки) | - 7 орфографических + 7 пунктуационных;<br>- 6 орфографических + 8 пунктуационных;<br>- 5 орфографические + 9 пунктуационные;<br>- 8 орфографические + 6 пунктуационные |
| Словарный | 0 | 1 - 2 | 3 - 4 | до 7 |

| Оценка | Основные критерии оценки сочинений и изложений | |
|---|---|---|
| | **Содержание и речь** | **Грамотность** |
| **«5»** | 1. Содержание работы полностью соответствует теме.<br>2. Фактические ошибки отсутствуют; в изложении сохранено не менее 70% исходного текста. Содержание работы излагается последовательно.<br>3. Текст отличается богатством лексики, точностью употребления слов, разнообразием синтаксических конструкций.<br>4. Достигнуты стилевое единство и выразительность текста.<br>5. Допускается 1 недочет в содержании. | Допускается:<br>1 негрубая орфографическая или 1 пунктуационная или 1 грамматическая ошибка |

| | | |
|---|---|---|
| «4» | 1. Содержание работы в основном соответствует теме, имеются незначительные отклонения от темы. Содержание в основном достоверно, но имеются единичные фактические неточности; при этом в работе сохранено не менее 70% исходного текста.<br>2. Имеются незначительные нарушения последовательности в изложении мыслей.<br>3. Лексический и грамматический строй речи достаточно разнообразен.<br>4. Стиль работы отличается единством и достаточной выразительностью.<br>5. Допускается не более 2 недочетов в содержании и не более 3 – 4 речевых недочетов. | Допускаются:<br>- 2 орфографические + 2 пунктуационные + 3 грамматические;<br>- 1 орфографическая + 3 пунктуационные + 3 грамматические;<br>- 0 орфографических + 4 пунктуационные + 3 грамматические. |
| «3» | 1. Имеются существенные отклонения от заявленной темы.<br>2. Работа достоверна в основном своем содержании, но в ней допущены 3 – 4 фактические ошибки. Объем изложения составляет менее 70% исходного текста.<br>3. Допущено нарушение последовательности изложения. Лексика бедна, встречается неправильное употребление слов. Речь недостаточно выразительна.<br>4. Допускается не более 4 недочетов в содержании и 5 речевых недочетов | Допускаются:<br>- 0 орф. + 7 пунк.;<br>- 1 орф. + 4-7 пунк. + 4 грам.;<br>- 2 орф. + 3-6 пунк. + 4 грам.;<br>- 3 орф. + 5 пунк. + 4 грам.;<br>- 4 орф. + 4 пунк. + 4 грам. |
| «2» | 1. Работа не соответствует заявленной теме.<br>2. Допущено много фактических неточностей; объем изложения составляет менее 50% исходного текста; нарушена последовательность изложения мыслей во всех частях работы, нет связи между ними. Текст не соответствует плану.<br>3. Лексика бедна. Работа написана короткими однотипными предложениями, часты случаи неправильного употребления слов.<br>4. Нарушено стилевое единство текста.<br>5. Допущено 6 недочетов в содержании и до 7 речевых недочетов | Допускаются:<br>- 5 и более грубых орфографических ошибок независимо от количества пунктуационных;<br>- 8 и более пунктуационных ошибок независимо от количества орфографических. |
| | | |

**Виды деятельности учащихся на уроке:**

-анализ языковых единиц с точки зрения правильности, точности и уместности их употребления;

- разные виды разбора (фонетический, лексический, словообразовательный, морфологический, синтаксический, лингвистический);

- лингвистический анализ языковых явлений и текстов различных функциональных стилей языка;

- **смысловой анализ и информационная переработка** устного и письменного текста:

составление плана текста;

пересказ текста по плану;

продолжение текста;

редактирование;

конспектирование;

-участие в диалогах различных видов;
- **аудирование** (понимание коммуникативных целей и мотивов говорящего; понимание на слух информации художественных, публицистических, учебно-научных, научно-популярных текстов , установление смысловых частей текста, определение их связей);
-**создание собственных письменных текстов**;
- составление орфографических и пунктуационных упражнений самими учащимися;
- составление опорных схем и таблиц;
**- работа с учебно- научными текстами, справочной литературой** и другими источниками информации, включая СМИ, компьютерные диски и программы, ресурсы Интернета;

**Дополнительная литература:**

Сафиуллина Ф.С. Современный татарский литературный язык. Лексикология. - Казань: «Хэтер», 1999. – 288 с.
Сатаров Г.Ф. Методика преподавания татарского языка в школе. - Казань: «Мэгариф», 2002. – 322 с.
Сафиуллина Ф.С. Язык мой – друг мой (на татарском языке). - Казан: Книжное изательство Татарстана, 1979. – 136 с.
Максимов Н.В. Тесты по татарскому языку. – Казань: «Мэгариф», 2002. – 159 с.
Салимгареева Б.С., Юлмухаметов М.Б. Сборник диктантов по татарскому языку для 5-9 классов (на татарском языке). – Уфа: «Китап», 1998. – 152 с
ГыймадиеваН.С.Диктантларһәмизложениеләржыентыгы»Яңалиф,».,2006
Харисова Ч.М.Язма эшләр жыентыгы».Мәгариф”,2004
Галлямова.Р.Сборник правил по татарскому языку.”Гыйлем,2011”
http//Tatar.com.ru
http//Tatarca.boom.ru
http//suzlek.ru
http//tataroved.ru